СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2024 г. Агрыз № 42-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасының йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында»19.11.2021 елның 12-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү йөкләмәләрен бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма үтәвенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 19.11.2021 елның 12-4 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 14.11.2023 № 32-5 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген әлеге карарга кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә.

2.Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә һәм үзара хезмәттәшлек буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль
районы Советының
13.12.2024 елның 42-2 номерлы
карарына кушымта

Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча йөкләмәләрне үтәвенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Бер үк җылылык белән тәэмин итү объектларында өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк авария булган.

2. Өч ай рәттән җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы мәсьәләләре буенча кулланучылардан ике һәм аннан күбрәк мөрәҗәгатьләр, шулай ук җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешма белән җылылык энергиясен кулланучы арасында килеп чыга торган каршылыклар килү.

3. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чаралары исемлеген үтәмәве турында мәгълүмат алу.

4. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру срокларын бозуы турында мәгълүмат керүе.